МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.01.2024 Казан ш № 1

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 971 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 971 номерлы боерыгы ( Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 27 июнендәге 627 номерлы, 2022 елның 7 ноябрендәге 989 номерлы, 2023 елның 5 сентябрендәге 720 номерлы боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.01.2024 ел, №1 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 971 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

түбәндәге эчтәлекле 2.3.3 пунктын өстәргә:

«2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы карарны үз эченә алган документлар реквизитлары:

хезмәт күрсәтүгә вәкаләтле органның атамасы;

хезмәт күрсәтү өчен вәкаләтле органның урнашу урыны адресы;

хезмәт күрсәтергә вәкаләтле органның телефон номеры;

хезмәт күрсәтү өчен вәкаләтле органның электрон почта адресы;

документның исеме;

карар кабул итү номеры һәм датасы;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

хезмәт күрсәтү турында карар кабул иткән органның вәкаләтле хезмәткәре вазыйфасы;

хезмәт күрсәтү турында карар кабул иткән органның вәкаләтле хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.»;

2.6.5 пунктта:

тугызынчы абзацта «Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмат системасы» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләре белән алмаштырырга;

унтугызынчы абзацта «Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмат системасы» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләре белән алмаштырырга;

3 бүлектә:

3.4.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Халыкның мәшгульлек үзәгендә теркәлгән гариза рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче турында дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органнар, муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган органнар,

бюджетка карамаган дәүләт фондлары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына карый торган оешмалар карамагында булган түбәндәге белешмәләрне сората:

паспортның чынлыгы турында мәгълүматлар – Россия Федерациясе Эчке Эшләр министрлыгында (ведомство мәгълүмат системасы);

яшәү (тору) урыны буенча теркәү турында белешмәләр – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгында (ведомство мәгълүмат системасы);

хезмәт эшчәнлеге турында, хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондында (ведомство мәгълүмат системасы);

иминият стажы турында мәгълүмат – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондында (ведомство мәгълүмат системасы);

соңгы эш (хезмәт) урыны буенча түләүләр турында һәм башка бүләкләү турында белешмәләр, шул исәптән мәҗбүри пенсия иминиятләштерүенә иминият кертемнәре күчерелгән белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондында (ведомство мәгълүмат системасы);

инвалидлык турында белешмәләр (инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасыннан өземтә (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта) – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондында («Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы);

белем, квалификация турында белешмәләр – Белем һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә («Белем турында документлар һәм (яки) квалификация, белем алу турында документлар турында бердәм белешмәләр федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы);

пенсия алды яшендәге гражданнарга кертелү турында мәгълүматлар – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондында («Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр – Федераль салым хезмәтендә (Юридик затларның бердәм дәүләт реестры);

Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр – Федераль салым хезмәтендә (Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестры);

юридик затларны гамәлгә куючылар (катнашучылар) булган гражданнар турында белешмәләр – Федераль салым хезмәтендә (Юридик затларның бердәм дәүләт реестры);

һөнәри керемгә салым түләүче (үзмәшгуль) статусы турында белешмәләр – Федераль салым хезмәтеннән («Һөнәри керемгә салым түләүче (үзмәшгуль) статусын тикшерү» гавами сервисы);

адвокат статусы турында белешмәләр – Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында (Россия Федерациясе субъектлары адвокатлары реестры);

нотариус вәкаләтләре һәм квалификация имтиханын тапшырган затлар турында белешмәләр – Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында (нотариуслар һәм квалификация имтиханын тапшырган затлар реестры);

бала туу турында белешмәләр (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта) – Федераль салым хезмәтендә (Гражданлык хәле актлары язуларының бердәм дәүләт реестры);

гражданинның үлеме турында белешмәләр – Федераль салым хезмәтендә (Гражданлык хәле актлары язуларының бердәм дәүләт реестры);

пенсия алу факты турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондында (ведомство мәгълүмат системасы);

гражданнарны ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар категориясенә кертү турында мәгълүмат (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта) – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондында («Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы);

вакытлыча эшкә яраксызлык чоры турында мәгълүмат – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондында (ведомство мәгълүмат системасы).

Әлеге органнарга ведомствоара гариза ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә гариза кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: ведомствоара гаризалар җибәрү.»;

3.4.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатькә җавап нәтиҗәсе булган белешмәләр (документлар) яисә соралган белешмәләрнең булмавы турында халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрелгән хәбәр.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.».